| | |
|---|---|
| ЛЕНИНОГОРСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.08.2020 г.Лениногорск № 252

2019 елның 23 октябрендәге 208 номерлы Лениногорск шәһәр Советы тарафыннан расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлектәге бюджет процессы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм федераль бюджетны үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 02 апрелендәге 103 номерлы Федераль законы нигезендә Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2019 елның 23 октябрендәге 208 номерлы Лениногорск шәһәр Советы тарафыннан расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлектәге бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

47 статьяның 1 пункты, 50 статьяның 5 пунктындагы 1 абзацы, 6 статьяның 2 пункты, 50 статьяның 3 пункты 2021 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга;

29 статьяның 16 пунктындагы 5 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

29 статьяның 4 пунктында «һәм үтәлә» сүзләрен төшереп калдырырга;

24 статьяның 2 пунктында « һәм үтәлә» сүзләрен төшереп калдырырга;

29 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Гарантның принципалга регресс таләбе хокукын күздә тотмый торган муниципаль гарантия фәкать хуҗалык җәмгыяте йөкләмәләре, 100 процент акцияләре (өлешләре) җирлек милкендә булган муниципаль унитар предприятие йөкләмәләре генә тәэмин ителергә мөмкин.»;

29 статьяның 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кредит (заем, шул исәптән облигация) буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә торган муниципаль гарантия гарантның алдан язма ризалыгыннан башка үзгәрмәгән һәм (яисә) кредит (займ, шул исәптән облигация) чараларын максатсыз кулланмаган очракта, муниципаль гарантия тарафыннан тәэмин ителгән төп йөкләмә шартларын гарантның алдан язма ризалыгыннан башка үзгәртелә алмый торган төп йөкләмә шартларын үзгәрткән очракта гына Гарант тарафыннан чакыртып алынырга тиеш., Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) кредит шартнамәсе һәм кредит буенча муниципаль)гарантия бирү турындагы шартнамә нигезендә кредитор тарафыннан кредит акчаларының максатчан кулланылышын тикшереп тору гамәлгә ашырыла".

2. Әлеге карарның рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керүен билгеләргә.

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры Р. Г. Хөсәенов